**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАРЫ**

**2020 елның 14 декабре** **№ 22**

**«Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнарның милкенә түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында» 2020 елның 07 сентябрендәге 278 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясындагы 1 пункты һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы нигезендә бирелә торган җир участокларының иң чик минималь күләмен ачыклау максатларында **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. “Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру мизгелендә билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнарның милкенә түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы2020 елның 7 сентябрендәге 278 номерлы карарының 1пунктына “7,8” санын “5,7” санына алыштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**